РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«2» ноябрь 2020 ел г. Альметьевск № 1601

Әлмәт муниципаль районының гомуми
белем бирү учреждениеләрендә укучыларны
туклandыруны оештыру турында

Балаларны социаль яклау, аларның сәламәтлеген ныгыту, кайнар туклануны оештыру, гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларның сәламәтлеген саклау максатларында

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Социаль якланмаган гаиләләрдәге балаларга адреслы социаль ярдәм күрсәтү максатларында, ташламалы туклану өчен расланган субсидияләр чикләрендә кайнар туклану өчен түләүдән азат итәргә, укучыларның түбәндәге категорияләрен:

ятим балалар һәм опекага алынган балалар;

инвалид балалар;

социаль яклау органнары белешмәләре базасында торучы аз тәэмин ителгән гаиләләрдәге балалар;

социаль яклау органнары белешмәләре базасында тора торган, гаиләнең бер әгъзасына уртача айлык керем Татарстан Республикасында билгеләнгән минималь яшәү дәрәҗәсенең күләменнән түбәнрәк булган күпбалалы гаиләләрдәге балалар (алга таба - укучылар).

Социаль ярдәмнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасын (ЕГИССО) (алга таба - СЯБДМС) Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә һәм социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы билгеләгән форматлар нигезендә куллану юлы белән әлеге социаль ярдәм чаралары турында мәгълүмат бирүне тәэмин итәргә

Белем алучыларга социаль ярдәмнең естәмә чараларын күрсәтү турында мәгълүматны СЯБДМС Россия Федерациясе Хекүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә куллану юлы белән һәм СЯБДМС да билгеләнгән форматлар нигезендә алынырга мөмкин.

2. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының карарының үз көчләрен югалтуын танырга:

«Әлмәт муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыру турында» 2015 елның 31 декабрендәге 1581 номерлы;

«Әлмәт муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыру турында» 2015 елның 31 декабрендәге 1581 номерлы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 30 октябрендәге 1756 номерлы;

Зак. № 3063

«Әлмәт муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыру турында» 2015 елның 31 декабрендәге 1581 номерлы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 6 декабрендәге 1929 номерлы;

«Әлмәт муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыру турында» 2015 елның 31 декабрендәге 1581 номерлы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 30 мартындагы 425 номерлы;

«Әлмәт муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыру турында» 2015 елның 31 декабрендәге 1581 номерлы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 25 декабрендәге 2254 номерлы;

«Әлмәт муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыру турында» 2015 елның 31 декабрендәге 1581 номерлы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 10 июнендәге 1122 номерлы;

«Әлмәт муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыру турында» 2015 елның 31 декабрендәге 1581 номерлы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 31 декабрендәге 1581 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 3 сентябрендәге 1633 номерлы;

«Әлмәт муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыру турында» 2015 елның 31 декабрендәге 1581 номерлы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 11 ноябрендәге 1973 номерлы карары;

«Әлмәт муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыру турында» 2015 елның 31 декабрендәге 1581 номерлы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 10 мартындагы 323 номерлы;

«Әлмәт муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыру турында» 2015 елның 31 декабрендәге 1581 номерлы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 10 августындагы 1111 номерлы;

«Әлмәт муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыру турында» 2015 елның 31 декабрендәге 1581 номерлы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 31 августындагы 1283 номерлы.

3. Көненә бер укучыга ата-ана кертемнәре (взнос) суммасын билгеләргә:

шәһәр һәм авыл гомуми белем бирү учреждениеләренең 5-11 сыйныфларында укучылар өчен 44 сум 15 тиен;

озайтылган көн төркеменә йөрүче гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны өстәмә тукландыру ечен 25 сум 00 тиен.

4. Билгеләргә:

шәһәр һәм авыл гомуми белем бирү учреждениеләренең 1-4 сыйныфларында укучылар өчен бер укучыга бушлай кайнар туклану бәясе көненә 51 сум 85 тиен;

Шәһәр һәм авыл гомуми белем бирү учреждениеләренең 5-11 сыйныфларында укучылар ечен бер укучыга баланслы кайнар туклану бәясе көненә 51 сум 85 тиен;

озайтылган кен төркеменә йерүче гомуми белем учреждениеләрендә бер укучыга естәмә туклану бәясе көненә 25 сум 00 тиен;

лицей-интернатта тәрбияләнүче бер укучыга баланслы кайнар туклану бәясе көненә 142 сум 00 тиен.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елга айлык акчалата һәм башка тер түләүләр турында» 2019 елның 28 августындагы 724 номерлы карары нигезендә уку елы дәвамында бер укучыга исәпләнгән акчалата түләүләр бәясе көнгә 7 сум 70 тиен күләмендә. Баланслы туклану нормативына туры китереп, аерма укучыларның ата-аналары хисабына түләнә.

5. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына (Шәйдуллина З.Р.) Әлмәт муниципаль районы мәгариф учреждениеләрендә балаларны һәм яшүсмерләрне тукландыруга үз вакытында акча бүлеп бирүне «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм турында» 2004 елның 08 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

6. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы мәгариф идарәсенә (Павловская И.А.) баланслы туклану нормативлары нигезендә гомуми белем бирү учреждениеләре укучылары өчен ашханәләрдә кайнар ризык әзерләүне оештыруны тәэмин итәргә.

7. Әлмәт муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләрендә социаль якланмаган гаиләләрдәге укучыларны тукландыруны оештыру тәртибе турындагы нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).

8. Район Башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

9. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2020 елның 1 ноябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

10. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С.В. Лаптевага йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе — М.Н. Гирфанов

ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ

Әлмәт муниципаль районы
Башкарма комитетының
«_2_» ноябрь 2020ел №1601
карары белән расланган
1 нче кушымта

## Әлмәт муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләрендә социаль якланмаган гаиләләрдәге укучыларны тукландыруны оештыру тәртибе турында НИГЕЗЛӘМӘ

1. Әлеге нигезләмә Әлмәт муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләрендә социаль якланмаган гаиләләрдән балаларның кайнар туклануын оештыру максатларында эшләнде. Укучылар категорияләре:

ятим балалар һәм опекага алынган балалар;

инвалид балалар;

социаль яклау органнары белешмәләре базасында торучы аз тәэмин ителгән гаиләләрдәге балалар;

социаль яклау органнары белешмәләре базасында тора торган, гаиләнең бер әгъзасына уртача айлык керем Татарстан Республикасында билгеләнгән минималь яшәү дәрәҗәсенең күләменнән түбәнрәк булган күпбалалы гаиләләрдәге балалар(алга таба - укучылар).

Социаль якланмаган гаиләләрдән балаларга адреслы социаль ярдәм расланган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә кайнар туклану өчен түләүдән азат итү юлы белән гамәлгә ашырыла.

2. Укучыларны ашату 51 сум 85 тиен күләмендә оештырыла.

3. Әлеге нигезләмәнең 1 пунктында санап үтелгән укучыларны кайнар тукландыруны оештыру өчен гомуми белем бирү учреждениеләрендә комиссия төзелә, аның составына педагогик коллектив һәм ата-аналар комитеты вәкилләре арасыннан укучыларны тукландыруны оештыру өчен җаваплы директор керә. Комиссия әгъзаларының гомуми саны кимендә биш кеше булырга тиеш.

Комиссия:

социаль яклау органы тарафыннан 15 августка, тиешле елның 15 гыйнварына бирелгән реестр нигезендә укучыларның исемлекләрен раслый;

тәкъдим ителгән гаризаларны карый һәм укучыларны өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗлар исемлегенә кертү турында карарлар кабул итә;

раслый торган документлар булган очракта, категорияләр буенча өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ укучыларның исемлекләрен раслый.

4. Сыйныф җитәкчеләре:

ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) бушлай туклану өчен гариза алалар (2 нче кушымта);

гаризаны алган кеннән соң өч көн эчендә комиссия каравына җибәрәләр;

категорияләр буенча сыйныфта укучыларның туклануын исәпкә алып баралар;

укучылар һәм аларның ата-аналары (законлы вәкилләре) арасында тулы кыйммәтле туклану кирәклеге турында аңлату эшләре алып баралар;

барлык укучы сыйныфларның ашханәсендә булуын тикшереп торалар;

Укучылар сыйныфының туклануы вакытында ашханәдә булалар.

5. Ата-аналар (законлы вәкилләр) бирелгән документларның дөреслеге өчен җаваплы. Гаризада күрсәтелгән укучыларның ата-аналары (законлы вәкилләре) тарафыннан документлар бирелмәгәндә, учреждение укучыларга ташламалы туклану бирүдән баш тарта.

6. Учреждение директоры:

- укучыларны бушлай кайнар туклану белән тәэмин итүгә категорияләр буенча боерыклар чыгара;

- Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы мәгариф идарәсенә категорияләр буенча укучыларның исемлекләрен тапшыра.

7. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы мәгариф идарәсе укучыларны туклandыруны оештыру, азык әзерләү технологиясен үтәү, ашамлыкларны чыгару, санитария нормаларын һәм гомуми белем бирү учреждениесенә барып азык әзерләү кагыйдәләрен үтәү мәсьәләләрен җитәкли.

8. Әлеге нигезләмә Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләренә кагыла.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесенең
социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С.В. Лаптева

Әлмәт муниципаль районы
Башкарма комитетының
«____» _______ 20__ ел №__
карары белән расланган
2 нче кушымта

__________ гомуми белем бирү мәктәбе
директорына
Ф.И.О. ______________________________
кемнән
Ф.И.О.____________________________
(укучының ата-анасы)
Адресы буенча яшәүче:
_____________________________________
_____________________________________

ГАРИЗА

Минем улыма (кызыма) _________________________нчы сыйныф укучысы _______________________________ ташламалы туклану бирүегезне үтенәм.

_____________________________
(дата, имза)

Гаризага теркәлә:
1.Күпбалалы гаилә турында таныклык күчермәсе.
2. Опека һәм попечительлек бүлегеннән белешмә, яисә балигъ булмаганнарга опека билгеләү турында күрсәтмәнең күчермәсе.
3.Инвалидлык билгеләү турында белешмә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесенең
социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С.В. Лаптева